ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Әлки муниципаль районы**
**Аппак авыл җирлеге**
**Советы**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Совет Аппаковского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Аппак авылы, Тынычлык урамы,1 йорт
Тел/Факс 8 (84346) 76443

422888, РТ, Алькеевский район,
с.Аппаково, ул.Мира, д.1
Тел/Факс 8 (84346) 76443

**РЕШЕНИЕ** Аппак авылы **КАРАР**

2024 нче елның 13 нче ноябре 107 №

2022 елның "15" декабрендәге Әлки муниципаль
районы Аппак авыл җирлегенең
59 номерлы «Әлки муниципаль районы
Аппак җирле үзидарә муниципаль
берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре,
депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә
гамәлгә ашыручы үзидарәләрнең,
хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында
Нигезләмәне раслау турында"гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 28 нче мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы 182№ (2018нче елның 24 апрелендәге 281№, 2018нче елның 14нче июнендәге 481№, 2018нче елның 17нче октябрендәге 940№, 2018нче елның 29нчы декабрендәге 1320№, 2021нче елның 17нче ноябрендәге 1087№, 2021нче елның 13нче декабрендәге 1222№, 2022нче елның 17нче сентябрендәге 1015№, 2024нче елның 30нчы апрелендәге 290№, 2024нче елның 24нче июнендәге 451№, 2024нче елның 25нче сентябрендәге 829№ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Әлки муниципаль районы Аппак җирле үзидарә Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елның 15нче декабрендәге Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 59 номерлы карарына (2024 елның 16 маендагы 93 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта түбәндәге абзац өстәргә:

01.01.2025 елдан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Аппак авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл

җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләменә бер тапкыр исәпләнә, ул 13 990 сум тәшкил итәчәк.

2. 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru.рәсми порталында бастырып чыгарырга

4.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге
Советы рәисе И.Х.Әбҗәббарова

2024нче елның 13 нче ноябрь
Әлки муниципаль районы Аппак
җирле үзидарә Советының
107 нче карарына
1нче кушымта

**2025 НЧЕ ЕЛНЫҢ 1НЧЕ ГЫЙНВАРЕННАН ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АППАК ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕНДӘ ДЕПУТАТЛАРНЫ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫ, АППАК ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК БАШЛЫГЫНЫҢ АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | авыл җирлекләрендә |
| | 12 нчы төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 13 991 |
| Депутат | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 13 990 |